Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев,
Н.Н. Хаҗипов,
И.Р. Нурсәетов
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы Экология кодексының**
**83 һәм 98 статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 86 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 47 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 75 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2026, № 1 (I өлеш), № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 83 статьяның 2 өлешендә «җирлекләр, шәһәр округлары» сүзләрен «муниципаль берәмлекләр» сүзләренә алмаштырырга;

2) 98 статьяның 13 өлешендә:
а) 4 пунктка «, шулай ук Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясындагы $16^4$ өлеше нигезендә рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен каралган объектларны булдыру чорына автомобиль транспорты транспорт чаралары хәрәкәте» сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:
«9) федераль законнарда каралган очракларда башка эшчәнлек.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 1 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**Татарстан Республикасы Экология кодексының 83 һәм 98 статьяларына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясындагы 15 өлешенең 4 пунктында билгеләнгәнчә, су саклау зоналары чикләрендә транспорт чаралары (махсус транспорт чараларыннан тыш) хәрәкәте һәм туктап торулар (моңа аларның юллардагы хәрәкәте һәм юллардагы, каты өслекле махсус җиһазландырылган урыннардагы туктап торулары керми) тыела.

Әлеге тыю шулай ук Татарстан Республикасы Экология кодексының 98 статьясындагы 13 өлешенең 4 пунктында да чагылыш таба.

2026 елның 9 гыйнварыннан үз көченә кергән «Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясына һәм «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» Федераль законның 38 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 558-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясына үзгәрешләр кертелде, алар рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар төзелгән чорда автотранспорт чараларының су саклау зоналары чикләрендә каты өслекле юллардан файдаланмыйча да хәрәкәт итү мөмкинлеген билгеләүгә юнәлдерелгән.

Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясына $16^4$ өлеш өстәлде, анда билгеләнгәнчә, рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектларны төзү чорына автомобиль транспорты чаралары хәрәкәте өчен су саклау зоналары чикләрендә гомуми файдалану өчен булмаган юллар, шул исәптән урман юллары булдыру рөхсәт ителә, ләкин су саклау зоналарын һәм су объектларын пычратуны, чүпләүне, суларына ләм утыруны һәм суның сыйфатын начарайтуны булдырмау, шулай ук су биологик ресурсларының, башка хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларының яшәү тирәлеген саклауга юнәлдерелгән чаралар (мондый юлларга агач, бетон плитәләр түшәү, таш яисә гравий салу) үткәрү шарты куела. Мондый юллар, кирәге беткәч, юкка чыгарылырга, ә алар урнашкан җирләр – рекультивацияләнергә тиеш.

Закон проектында Татарстан Республикасы Экология кодексының 98 статьясындагы 13 өлешенең 4 пунктына үзгәреш кертү һәм Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясындагы $16^4$ өлеше нигезендә рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектларны төзү чорында автомобиль транспортының транспорт чаралары хәрәкәте мөмкинлеген билгеләү тәкъдим ителә.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Экология кодексының 98 статьясындагы 13 өлешенә яңа нигезләмә өстәргә тәкъдим ителә, аның нигезендә әлеге өлештә күрсәтелгән тыюлардан тыш, федераль законнарда каралган очракларда су саклау зоналары чикләрендә башка эшчәнлек тыела.

Шулай ук закон проектында Татарстан Республикасы Экология кодексының 83 статьясында шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырганда атмосфера һавасын саклау таләпләрен билгели торган «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законга «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Федераль законның 7 статьясына һәм Россия Федерациясе аерым

закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 578-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән төгәлләштерү характерындагы үзгәрешләрне дә исәпкә алу тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының 83 һәм 98 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының 83 һәм 98 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының 83 һәм 98 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының 83 һәм 98 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.